КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 30 июль г.Казань № 618

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карар белән расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 25 ноябрь, 908 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 март, 151 нче; 2016 ел, 18 июнь, 414 нче; 2016 ел, 09 ноябрь, 834 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану, гражданның социаль хезмәтләр күрсәтүгә шәхси ихтыяҗларын билгеләү һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзү Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсе (бүлеге) (алга таба – Министрлыкның территориаль органы) яки Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау

министрлыгы карамагында булган, аңа Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасының бер яки берничә муниципаль берәмлекләре территорияләрендә гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тануга һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең шәхси программасын төзүгә вәкаләтләр бирелгән оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле оешмалар исемлеге Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән раслана.»;

4 нче пунктта «Гражданны» сүзен юл хәрефеннән язарга һәм аның алдына «Министрлыкның территориаль органы тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

6 нчы пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«социаль хезмәт күрсәтүдә мохтаҗ булу турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар (документлар күчермәләре) теркәлгән социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны (мөрәҗәгатьне) кабул итү һәм теркәү;»;

дүртенче абзац үз көчен югалткан дип санарга;

7 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Министрлыкның территориаль органына гражданның яшәү урыны (тору урыны) буенча яки вәкаләтле оешмага Татарстан Республикасында яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлгән гражданның яки аның законлы вәкиленең язма йә электрон рәвештә тапшырылган социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризасы яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар мөрәҗәгате, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгате йә ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында тапшырылган социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза яки мөрәҗәгать социаль хезмәт күрсәтү турындагы мәсьәләне карап тикшерү өчен нигез булып тора. Яшәү урыны (тору урыны) буенча теркәлү турындагы шарт яшәү урыны билгесез булган затларга, шулай ук законнар белән күздә тотылган очракларда балигъ булмаганнарга кагылмый.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны тапшырганда граждан шәхесен раслый торган документ күрсәтә. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза законлы вәкил тарафыннан тапшырылганда йә граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре мөрәҗәгать иткәндә вәкилнең шәхесен һәм вәкаләтләрен раслый торган документлар күрсәтелә.»;

бишенче абзацны төшереп калдырырга;

8 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза һәм документлар Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан кабул ителә.

Гаризада (мөрәҗәгатьтә) күрсәтелгән социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ булуга бәйле булган хәлләрне раслый торган документлар (документлар күчермәләре) социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза (мөрәҗәгать) белән бергә – граждан (аның законлы вәкиле) тарафыннан, ә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре

мөрәҗәгать иткән очракларда – башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан (ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән очраклардан тыш) тапшырыла.

Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече граждан (законлы вәкил) мөрәҗәгать иткән яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр вәкилләре мөрәҗәгать иткән көндә гаризаны һәм тапшырылган документларны (документлар күчермәләрен) тикшерә.

Бу Тәртипнең 9 нчы пунктындагы таблицада күрсәтелгән һәм «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлештә санап үтелгән документлар категориясенә кертеп каралган документлар (документлар күчермәләре) кертелмәгән очракта, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гариза белән мөрәҗәгать иткән көндә гражданга (законлы вәкилгә), башка гражданга, дәүләт органына, җирле үзидарә органына, иҗтимагый берләшмәгә (граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләр булу турында хәбәр итә һәм, гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең асылын аңлатып, социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны һәм документларны (документлар күчермәләрен) кире кайтара.

Граждан (законлы вәкил), башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан (граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тапшырылган документлар һәм мәгълүматлар («Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-210 нчы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлештә санап үтелгән документлар категориясенә кертеп каралган документлардан тыш) җитәрлек булмаган очракта, гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле документлар һәм мәгълүматлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) тарафыннан сорала.

Министрлыкның территориаль органы белгече социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны теркәлгән документлары белән теркәүгә алган көндә аларны бу Тәртипнең бишенче – җиденче абзацлары белән күздә тотылган эшләрне үткәрү өчен Учреждениегә тапшыра.»;

9 нчы пунктта:

беренче абзацта «Министрлыкның территориаль органы» сүзләреннән соң «(вәкаләтле оешма)» сүзләрен өстәргә;

таблицаның 1 пунктындагы 3 графаның икенче абзацында «социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү өчен медицина ягыннан зарарлы булуын күрсәтә торган билгеләр булу (булмау)» сүзләрен төшереп калдырырга;

10 нчы пунктта:

беренче абзацка «(вәкаләтле оешма)» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацка «Учреждениегә» сүзләреннән соң «(вәкаләтле оешмага)» сүзләрен өстәргә;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар проекты әзерләнә, ул, гариза тапшырган (мөрәҗәгать иткән) көннән дүрт эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесенә раслауга җибәрелә.»;

11 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы (танудан баш тарту турындагы) карар (алга таба – карар), гариза тапшырылган (мөрәҗәгать иткән) көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесе тарафыннан кабул ителә. Карар Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белән расланган форма буенча кәгазь йөрткечтә рәсмиләштерелә һәм электрон рәвештә мәгълүмат системасына кертелә. Карар аңа Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесе имзасы куелган көндә Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә тапшырыла.»;

12 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече, гариза тапшырылган (мөрәҗәгать иткән) көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, гражданга (законлы вәкилгә), башка гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) кабул ителгән карар турында гаризада күрсәтелгән почта яки электрон адреска язма яки электрон рәвештә хәбәр итүне гамәлгә ашыра. Уңай хәл ителгән очракта, гражданга (законлы вәкилгә) бер үк вакытта социаль хезмәтләр күрсәтүнең индивидуаль программасын төзү датасы һәм аны төзү урыны турында хәбәр ителә.»;

17 нче пунктка «Учреждение» сүзеннән соң – «(вәкаләтле оешма)» сүзләрен, «граждан» сүзеннән соң «(законлы вәкил) яки башка граждан, дәүләт органы, җирле үзидарә органы, иҗтимагый берләшмә (граждан мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда)» сүзләрен өстәргә;

19 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Индивидуаль программа ике нөсхәдә төзелә. Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесенең имзасы куелган индивидуаль программа нөсхәсе гражданның (законлы вәкилнең) гариза тапшырган яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар мөрәҗәгать иткән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр социаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать иткән көннән иң күбе 10 эш көне эчендә гражданга тапшырыла.»;

22 нче һәм 23 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесе тарафыннан гражданны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турындагы карарга имза куелган көннән өч эш көне чыкканга кадәр, әмма граждан (законлы вәкил) тарафыннан гариза тапшырылган яисә аның мәнфәгатьләрендә башка гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән көннән иң күбе сигез эш көне эчендә Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече тарафыннан индивидуаль программа проектын әзерләү гамәлгә ашырыла, аны карап тикшерү һәм имза кую өчен Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесенә җибәрелә.

23. Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) җитәкчесе Учреждениедән индивидуаль программа проекты кергән (аны вәкаләтле оешма белгеченнән алган) көннән бер эш көне эчендә аны карауны, аңа кул куюны һәм гражданга (вәкаләтле органга) тапшыруны оештыру өчен Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрүне гамәлгә ашыра.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин